# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк ағыл җирлеге составына керүче Кәүҗияк торак пунктында 2021 елда үзара салым кертү турында

**2020 елның 13 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Кәүҗияк авылында гражданнар җыены

## КАРАР БИРДЕ:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге территориясендә Кәүҗияк торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, I төркем инвалидлардан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- Кәүҗияк т. п. урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу);
- газ 3512 махсуслаштырылган техникасын тоту(йөк үзбушаткычы): дизель ягулык-майлау, запас частьләр сатып алу;
- Кәүҗияк т. п. территорияне җәй көне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).;
- Кәүҗияк т. п., Совет ур.урнашкан зират коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу);
- Кәүҗияк т. п. Совет ур. буенча урнашкан зират территориясендә биек агачларны кисү(килешү буенча эшләр өчен түләү)
- район газетасы «Сарман»да некрологларны бастырып чыгару.

3. Әлеге карарны Кәүҗияк авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы Ф. Ә. Хөснетдинов